**СОВЕТ МУЛЬМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422731, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Мульма, ул. Центральная, 46а

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МҮЛМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422731, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Мүлмә авылы, Үзәк урамы, 46а

Тел./факс 8(84365)70-2-03, e-mail:Mulm.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**3 сентябрь 2020 ел** **№212**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге җирле үзидарә органының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнарына тапшыру турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.5 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлешенә, Мүлмә авыл җирлеге Советының 2019 елның 11 ноябрендәге 181 номерлы карары (2019 елның 13 декабрендәге 187 номерлы редакциясендә) белән расланган Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибенә, Мүлмә авыл җирлеге Уставы, Мүлмә авыл җирлеге Советы, Мүлмә авыл җирлеге

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Җирләүгә тарифлар билгеләү һәм җирләү эше өлкәсендә җирле үзидарә вәкаләтле органы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өлешендә ритуаль хезмәтләр оештыру буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнарына тапшырырга;
2. Әлеге карарны карау өчен Биектау муниципаль районы Советына җибәрергә.
3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесен вакытлыча башкаручы (Мухаметгалиева Лилия Наил кызы) Биектау муниципаль районы Советы карары кабул ителгәннән соң 10 календарь көннән дә артмыйча, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру турындагы килешү төзү буенча як булырга;
4. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталының рәсми сайтында: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе урынбасары,
Авыл җирлеге Башлыгы урынбасары Л.Р. Зиннәтуллин